# РОМАШКА

*ИФРАТ ХИСАМОВ музыкасы*
*МИРГАЛИМ ХАРИСОВ сүзләре*

Ап-ак күлмәгеңне киясең,
Назлы җилгә башың иясең.
Син, ромашкам, гашыйк күңелгә
Юаныч һәм шатлык бирәсең.

*Кушымта:*
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәү генә шикелле;
Йөрәгемдә утлар яна,—
Яратуы икеле.

Ал таң нурларына төренеп,
Тезелгәннәр синең чукларың;
Яратамы, юкмы, дигәндәй,
Чукларында уйный чыкларың.

*К у ш ы м т а.*

Моңсуланган чакта күңелем
Очратам да сине, куанам.
Җавап эзләп янган йөрәккә
Чукларыңны санап юанам

*Кушымта:*
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәү генә шикелле;
Йөрәгемдә утлар яка,
Болай булмый бит инде.
Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәү, алтау — ярата,
Үзе, наян, ярата да,
Юри генә шаярта.